**1978-1985 еллар.**

1978-1986 елларда мәктәптә һәм укытучылар коллективында күп кенә үзгәрешләр булды .

1978 нче елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлап, Наилә Гыйздуллина башлангыч класс укытучысы булып эшкә килә .

Шул көннән башлап, 1983 нче елга кадәр балалар укыта. Наилә күпкырлы сәләткә ия була. Балаларга ныклы белем бирү белән бергә, авылның культурасын үстерүдә дә зур тырышлык куя. Ул сәхнә остасы да була. Бик күп спектакльләрдә төп рольләрне башкара. Район газеталарына матур-матур шигырьләр яза.



Рәхилә Габдеразиевна Галина үзенең хезмәт юлын 1961 елда ук башлый . Укучыларга ул тарихтан һәм иҗтимагый фәннәрдән дәресләр бирә. Рәхилә укучылар белән класстан тыш тәрбия чараларын бик оста файдалана. Туган ягын өйрәнү буенча, тарихи урыннар белән танылу өчен, төрле походлар, сәяхәтләр оештыра. Галина авылның, колхозның җәмәгать тормышында да бик актив катнаша. Ул ата - аналар белән җитәкчелек итә. Партия мәгарифе системасы пропогандисты буларак, авыл коммунистларын политик белемнәр белән коралландыра.

Гомәрова Розалия Гомәровна пединститут бетергәннән соң мәктәпкә укытучы булып кайта һәм 1976 - 1977 уку елларында биология һәм география фәннәрен укыта.1978 нче елда мәктәпкә рус теле укытучысы Гилязова Зиряк Закариевна килә һәм бер ел рус теле фәнен укыта.



1978 нче елда Хакимова Нурия Фаязовна мәктәпкә пионерважатый булып эшкә килә. Кыска гына вакыт эчендә, сәләтле, кыю, пионер эшләренең остазы булып әверелә. Мәктәпнең пионер оешмасына кергән укучылар белән күпкырлы эш алып бара. Һәм 1980 нче елга кадәр узенең эшен дәвам иттерә. Нурия Хакимова мәктәптән икенче урынга күчкәннән соң, 1981-1982 елларда пионервожатый булып Исәнбай кызы Вагизова Альфира Насимовна эшли

Габбасова Гульфания Хазиевна 1977 елда башлангыч классларда укытучы булып эшләде.

Арсланова Әнисә 1972 елда мәктәпкә буфетчы булып килә һәм 1986 нчы елга кадәр шул эшендә эшли.

1976 елда армия хезмәтен бетергәннән соң, Рамазанов Ильфат Галиевич мәктәптә балаларга башлангыч хәрби хәзерлек фәнен укыта башлый. Укучыларны хәрби - политик белемнәр белән коралландыра, барлык көчен, энергиясен бирә. Һәм шушы эшен 1985 елга кадәр дәвам итә.

Назмиева Әлфия Габделнуровна 1979 - 1980 елларда математика, физика фәннәре укытучысы була. Султанов Ханиф Разиевич 1980 елда мастер производство булып эшли. Насыйрова Альфира Рифкатовна терлекчелек буенча укытучы булып эшли. Султанова

Дания Касимовна 1978 нче елда рус теле укытучысы булып кайта һәм бугенге көнгә кадәр рус теле фәнен укыта.Шаймарданов Назим 1978 елда мәктәпкә завхоз булып эшкә керә һәм 1985 нче елга кадәр шул эшендә эшли.Муллахметова Дилбәр Харисовна 1979 - 1980 елларда рус теле фәнен укыта. Гибадуллина Венера Габдулхаковна озайтылган көн группасында тәрбияче булып эшли.Мингалиева Клара география фәнен укыта.

1982 - 1984 елларда Габбасова Мөнзилә математика фәнен укыта. Тукманов Марат Гарипович физкультура укыта.

1978 елда Иске Эсләк авылы кызы Гөлдәния мәктәптә лаборант булып эшли. Ул киткәннән соң 1980 нче елдан алып бу эшне Ситдикова Зәнфирә Баяновна алып бара. Үзенең пөхтәлеге, төгәллеге белән ул бик тиз арада коллективның ихтирамын казана.

Даутова Фәһимә Закировна, 1983 елда пенсиягә чыгуына карамастан, һаман да балаларына химия фәненең серләренә өйрәтүен дәвам итә.1980 елдан алып Закирова Мөнирә мәктәптә авыл хуҗалыгы хезмәте фәнен һәм кызларны кул эшләренә өйрәтә.

Кадыбаш урта мәктәбе укучылары 1983 нче елның яңа елын яңа мәктәптә каршыладылар. Мәктәп бинасы “ Таң ” колхозы средствосына төзелә.




Заманча төзелгән, 320 урынлы ике катлы бу уку йортының иркен, якты һәм җылы класс кабинетларында авыл балалары фән нигезләрен өйрәнәләр.

Ә укыту тәрбия эшен бүгенге таләпләр югарылыгында алып бару өчен, үсеп килүче яшь буынны иҗтимагый файдалы хезмәткә хәзерләү өчен биредә бөтен шартлар да булдырылган 4-8 класс укучылары белән техник- хезмәт дәресләре үткәрү өчен катнаш мастерской җиһазландырылды. Мастерскойда агач эшкәртү өчен 12 столярлык станогы, металл эшкәртү өчен 12 махсус верстак, тишү, кыру, токарьлык, винт ясау станоклары һәм башка инструментлар бар. Боларны хезмәт укытучысы, директор Сафин Нургаян җиһазлады.Шушы ук классларлардагы кызлар өчен йорт эшләре кабинеты да бай җиһазландырылды. Газ плитәсе, духовкалы электр плитәсе, савыт - саба, аш һәм чәй сервизлары бар, биш тегү машинасы куелган. Кабинетны җиһазлау эшенә яшь укытучы Розалия Сафина җитди әһәмият бирә, ата-аналарның ярдәмен оста оештыра.

3 класслы тракторчы-машинист һөнәрен үзләштерү өчен дә кабинет җиһазландырыла. Анда МТЗ-50 тракторының тулысынча киселеше куела һәм ул электр двигателе белән редуктор аша хәрәкәткә китерелә. Монда үз эшенең остасы булган укытучы Мөхәмәтнур Әхмәдишинның зур хезмәте бар.

Исламова Зөлфия башта озайтылган көн группасында тәрбияче булып эшли. Соңыннан 1983 нче елдан башлап география, биология фәнен укыта. 1977-1978 елда Фатхиева Гөлсинә Мингалиевна лаборант булып эшләде.Тәрбиячеләр: Зәйнетдинова Заһидә, Шаймуратова Зәйнәп, Рашитова Ләлә. Библиотекарьлар: Ситдикова Зөлфия Һәм Закирова Мөнирә.Завхозлар: Ибраев Заһит, Шаймарданов Назим, Арсланов Зиннур .

Техничкалар: Хатбуллина Әнисә, Гилмутдинова Әкълимә, Гарифуллина Миннур, Гарифуллина Әкълимә, Башарова Зәйтүнә, Галимова Разия, Ахмадишина Флүрә., Шарипова Розалия, Шаймарданова Гәмбәрия, Мосифуллин Лотфулла.

Пионервожатыйлар: Хакимова Нурия , Габдрахманова Вәсилә, Абдуллина Зәйтүнә, Шакирова Гөлшат, Гимранова Розалия, Шакирова Рәсимә.